СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон (8552) 70-00-33, факс 70-12-61, tukay.rt@tatar.ru

31.08.2026 № 13/2

На №__________от______________

# КАРАР

**Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Тукай районы прокурорының 2026 елның 04 июнендәге 02-08-02-2026/777-26-20920036 номерлы протесты нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2018 елның 20 августындагы 27/6 номерлы карар белән расланган (Тукай муниципаль районы Советының 31.10.2025 ел, № 2/14 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлектә яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы карары белән төзелә. Күрсәтелгән акт белән комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.».

1.2. 2.2 пунктының «а» пунктчасын түбәндәге эчтәлектә яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.2. а) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгы урынбасары (комиссия рәисе), муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче зат (комиссия рәисе урынбасары), Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны

профилактикалау буенча җаваплы кадрлар хезмәте бүлекчәсе җитәкчесе (комиссия секретаре), Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының юридик бүлеге, җитәкчесе тарафыннан билгеләнә торган җирле үзидарә органының башка бүлекчәләре муниципаль хезмәткәрләре;».

1.3. 3.1 пункты «а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге эчтәлектә яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.1. а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәвен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә уздырылган тикшерү йомгаклары буенча дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан түбәндәгеләрне таныклаучы тикшерү материалларын тапшыру:

дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәдә каралган дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр бирү турында;

дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве турында.».

1.4. 3.7 пунктының «а» пунктчасын түбәндәге эчтәлектә яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.7. а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы булып тора.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе

К.Р. Нәҗмиев